Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең
Түбән Абдул авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

1 декабрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 30 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2023 елның 30 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең Түбән Абдул авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата – аналарыннан, хатыны, балаларыннан) тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы: су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган скважиналарны һәм башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау, торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 419 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 235 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 235 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең Түбән Абдул авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең Түбән Абдул авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата – аналарыннан, хатыны, балаларыннан) тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы: су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Түбән Абдул авылы, Ленин урамы, 92 йорт территориясендә урнашкан

махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Абдул авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Юнысов